СОВЕТ САРМАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

07.09.2020 с. Сарманово № 253

**Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмнәрен арттыру турында**

«Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләр башлыкларының, муниципаль берәмлекләр башлыклары урынбасарларының, җирле үзидарәнең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы сайланулы органнары әгъзаларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең һәм муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфаи окладларын ай саен акчалата түләү күләмнәрен арттыру турында» 2020елның 06 августындагы 658 номерлы карары, Татарстан Республикасы «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Сарман муниципаль районы Советы түбәндәгеләрне КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең акчалата гомуми хезмәт хакы турында» нигезләмә» 2018 елның 13 августындагы 130 номерлы Сарман муниципаль районы Советы карары белән билгеләнгән тәртиптә билгеләнә торган Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмнәрен (Сарман муниципаль районы Советының 2018 елның 10 декабрендәге 153 номерлы, 2020 елның 22 июнендәге 242 номерлы карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) 2020 елның 01 октябреннән арттырырга.

2. Сарман муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфаи окладларының күләмнәрен исәпләп чыгару өчен, әлеге карарның 1 пункты нигезендә авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларының кече төркеме белгеченең вазыйфаи оклады күләмен 1,03 тапкырга индексацияләргә һәм аны 11 498 сум күләмендә билгеләргә.

3. Әлеге карарны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү, тиешле финанс елына җирле бюджетларда каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

4. Җирле үзидарә органнары һәм муниципаль орган җитәкчеләренә алар чыгарган хокукый актларны әлеге карарга туры китерүне йөкләргә.

5. Әлеге карарны «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Сарман муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Муниципаль район
Советы рәисе Ф.М. Хөснуллин